БЕРДӘМ БУЛЫЙК!
Таркау халык ирек яулый алмый,
Аккош, чуртан, кысла кебекләр.
Ирек яулый фәкать бердәм халык,
Ирек яулый батыр егетләр.

Ирегe өчен көрәш үз халкыңның,
Дуслык өчен көчең җиткәнчә!
Ирек килер шиксез кочак белән
Безгә Борис Ельцин әйткәнчә!

Тыңлама син битарафлар сүзен
Миңа кайсы да бер дигәнне!
Тыңла сабыр, аек акыл белән
Илен, халкын, дуслык сөйгәнне!
1992

КЕМ ДИМ СИНЕ ?
Милләтең кем синең , Ибраһимов,
Әйтче, Артур Рудольфович?
Ибраһимов булгач татардыр син,
Артур булгач, бәлки инглиз?
Атаң синең немец булса кирәк,
Кем дияргә сине белмим һич.
-Авыр сорау куйдың минем алга,
Милләтемне ничек атарга?
Татарын мин болай татар инде,
Тик белмимен генә татарча.
Бала тугач, аңа исем эзләп
Ата-аналар ерак китәләр.
Безнең исемнәрне таптап узып
Лондонгача барып җитәләр.
Эзли алар яңа матур исем,
Ошатмыйча милли исемне.
Исем матур була шул чагында –
Матур булса аның җисеме!
Берәү малаена Вернер кушкан,
Шуны яңа исем дисезме?
Вернер инде ул – дистә гасыр йөргән
Бик искергән немец исеме.
Һәр халыкның гореф-гадәте бар,
Үзенә хас милли исеме.
Безнең Камил, Шамил, Илһамнарны
Шул Вернердан ямьсез дисезме?
Яшь сабыйга исем биргән чакта

Бөтен ягын ныклап уйлагыз.
Ят исем дип башка бер халыкның
Эт исемен кушып куймагыз!
1989

## ТУГАН ТЕЛЕМ – СӨЙГӘН ТЕЛЕМ

Туган телем, сөйгән телем – татар теле,
Гүя күңел бакчамдагы кышкар гөле.
Бу тел белән тәүге ачылган минем телем.
Шушы телдә мәктәпләрдә белем алдым.
Сөям аны туган илне сөйгән кебек,
Егет кызга: “ Җаным, бәгърем”, дигән кебек,
Туган телдә яңгыраган һәр җыр, моңны
Күңелем белән кочам кебек, үбәм кебек.
Кайберәүләр башка телдә көйләнәләр,
Үз телләрен кимсетәләр, җирәнәләр.
Читләштереп балаларын туган телдән.
Алар белән русча гына сөйләшәләр.
1988

## ТЫНЫЧ БУЛСЫН ДӨНЬЯЛАР

Изге Ватан өчен көрәш бара,
Кара төтен баскан күк йөзен.
Дошман атакасын кайтарабыз
Иртә таңнан алып без бүген.
Пушкалардан бөркеп ут чәчелә.
Җир тетери залпларыннан.
Кемнәр-кемне дигән кискен чакта
Дуслар килде шәрыкъ ягыннан.
Дошман атакасы кайтарылды,
Танклары яна кыр тулып.
Фашистларның корган планнары
Күккә очты тагын көл булып.
Тормышыбыз гөрләп чәчәк аткан
Шундый рәхәт, тыныч заманда.
Канга сеңеп калган сугыш кыры
Төшкә керә әле һаман да.
Сугыш беткәч күпме сулар акты,
Сыкрый әле һаман яралар.
Көтә һаман ирен тол хатыннар,
Улын көтә газиз аналар.
Без кичергән сугыш газапларын
Күрмәсеннәр безнең балалар.
Барлык йөрәкләрдә бердәм теләк –
Имин генә булсын дөньлар. 1979

## ЯДКАРЬ БУЛЫП ЯШЬЛӘРГӘ

Һәр язда без Җиңү бәйрәмендә
Җыелабыз изге урынга.
Һәйкәлләргә килеп баш иябез,
Үлгәннәргә сугыш кырында.
Хәтердә бит сугыш дәһшәтләре,
Үлемнәрне күргән мең юллар.
Йөрәкләргә мәңге җуелмаслык
Яра салган авыр ул еллар.
Без бәхетле, чөнки язмыш безгә
Бүләк итте ике гомерне:
Аның берсе узды сугышларда,
Икенчесе – бүген түгелме ?
Дошманнарга каршы көрәшләрдә
Бәйсезлеген илнең яуладык.
Гасырларга күчәр безнең исем –
Туар буыннарга юл салдык.
Дөньялар бит тыныч, тормыш рәхәт,
Тик яшәргә, бары яшәргә.
Ветераннар гына азаялар
Ядкарь булып җирдә яшәргә.

1987

## САГЫНДЫРА МИНЕ

Давыл тынды, Берлин күге зәңгәр
Без торабыз Ватан сагында.
Сагыну хисе әмма тынгы бирми,
Җанга көндез, кичен, таңында.
Сагындырды мине туган ягым,
Төшкә керә бала чакларым.
Кама буе, күлләр, төнбоеклар,
Бөдрә таллар, туган якларым.
Сагындырды мине зәңгәр урман,
Авылымның алсу таңнары.
Сагындырды мине таныш җырлар.
Үз халкымның талгын моңнары.
Сагындырды мине хәтфә болын,
Колхозымның иркен кырлары.
Сагындырды авылым егетләре,
Яулык болгап калган кызлары.
Сагындырды мине авылдашлар,
Улын көтеп калган аналар.
Сагындырды мине җиз кыңгырау,
Сумка тоткан нәни балалар.
Давыл тынгач, тыныч язлар килде,

Кошлар очты безнең якларга.
Кошлар белән яуда җиңеп чыккан
Дуслар кайтты туган якларга.
Киек казлар узды, кайталар, дип ,
Зәңгәр урман торды тын карап.
Авылдашлар безне каршы алды,
Җиз кыңгырау килде шалтырап.
Авыр еллар инде артта калды,
Ал таң атты авылым күгендә.
Матур кызның чәчәк тоттырганы
Күз алдымда әле бүген дә.
1978

## КАЯ КИТКӘН СОЛДАТ ЧАКЛАРЫМ

Әле япь-яшь солдат, музыкага басып,
Изге стройда атладым.
Карпат кызларына каш сикертеп узган
Кая икән солдат чакларым ?
Изге афәт килгәч, пушкалардан атып,
Туздырдык без дошман сафларын.
"Ур-ра!" тавышы белән атакага киткән
Кая икән солдат чакларым ?
Озын төннәр буе туң окоптан карап,
Изге Ватанымны саклaдым.
Авыру-сырхау белми, лачын кебек йөргән
Кая икән солдат чакларым?
Авыр сугышларда фашистларны куып
Көнбатышка таба атладым.
Автоматны асып, елга йөзеп чыккан
Кая икән солдат чакларым ?
Дошманнарны җиңеп, дөнья тыныч калгач,
Калдырдык без Берлин якларын.
Хыял диңгезендә Туган илгә кайткан
Кая икән солдат чакларым?
1983

## ВЕТЕРАННАР

Капка төбендәге утыргычта
Шәех бабай сөйли күргәнен.
Дүрт ел буе каты сугышларда
Ниләр булган, кайда йөргәнен.
"Сугышта мин минометчы идем,
Менә корал да ул миномет.
Фашистларны дер селкетә идек,
Көтмәгәндә ачып аннан ут.

Аның белән игезәк балалардай,
Бергә йөрдек һәрчак икәүләп.
Фашистлардан сугыш кырында.
Батыр дигән медаль алып бирде
Көрәшләрдә Дунай ярында.
Ветераннар бар да минем кебек,
Сөйлиләрдер сугыш елларын.
Ветераннар һаман шинель киеп,
Узалардыр сугыш елларын.
Иңемә алып аны, балам кебек,
Европаны уздым җәяүләп.
Ничә тапкыр мине коткарды ул,
Ветераннар, горур ветераннар,
Ерак калды солдат еллары
Ил аларны мәңге яклап сөйләр,
Якты маяк – узган юллары.
Онытмаслар безне улларыбыз,
Хәтта, оныкларның уллары.
Горурланып алар искә алыр
Бабалары узган юлларны.
Дошман коллыгына төшермәскә,
Һәр киләчәк өчен йөрделәр.
Ветераннар халык ирке өчен
Сугышларда утка керделәр.
Менә тиздән кырык еллар җитәр,
Бәйрәме дә булыр, бәйрәме.
Трибунага чыгып без сөйләрбез.
Кулга тотып чәчәк бәйләме”.
...Тыныч узган кырык ел эчендә
Илем гөлбакчага әйләнде.
Зәңгәр күктә ак күгәрчен оча,
Каршылыйм дип, гүя бәйрәмне.
Бүген бәйрәм! Биек башняларда
Җилфердиләр кызыл әләмнәр.
Дөнья халкы безне тәбрик итә.
Радиодан яңгырый сәламнәр.
Ветераннар кайта митингтан ,
Кулларында чәчәк бәйләме.
Шәех бабай гына китеп барды,
Күрә алмый бу зур бәйрәмне.
1985

МӨМКИН ТҮГЕЛ ОНЫТУ
Изге Ватан өчен сугышларда
Үлем яки тормыш дигәндә
Батыр дуслар була таянычың,
Дошман сөңге сузып килгәндә.
Кат-кат укып бергә сөйләшәсең
Хатлар алсаң туган ягыңнан.
Шундый дустым булды армиядә
Майна егете Биләр ягыннан.
Шат күңелле батыр егет иде,
Күңеле төшенкелек белмәде.
Газетада һәрчак чыгып торды
Насыйровның көрәш үрнәге.
Гаубицасын төзәп аткан саен
“Фашист, мә бер кыяр”, - дия иде,
Снарядны туры барып төшкәч
Гаубицасын мактап сөя иде.
Менә рәхмәт сиңа, тегеләрнең
Эзләгәнен бик тиз таптырдың.
Ерак ыргытсаң да кулың туры,
Кирәк җирләренә каптырдын.
Шулай бер төн фашист өерләре
Безнең өскә дәррәү куптылар.
Танклары үкереп өскә килде,
Пушкалардан утка тоттылар.
Снарядлар шартлый алда, артта,
Күтәрелә җирдән ком-тузан.
Шул сугышта дустым һәлак булды
Дошман снаряды шартлаудан.
Дәһшәт эчендә мин эзләп таптым
Авыр яраланган дустымны.
Кулларымны кысып саубуллашты,
Соңгы амәнәтен тапшырды.
“Изге Ватан өчен һәлак булам,
Шушы тауда мине җирләрсең.
Исән кайтсаң минем вакыйганы
Туганнарга барып сөйләрсең”.
Взводаны соңгы юлга озатып
Салют бирде елга ярында.
Юлгаттым мин дустым Габдулланы
Матур җәйнең алсу таңында.
Пилоткамны салып башым иеп
Озак тордым кабер янында.
Уйлар узды баштан бер-бер артлы
Бергә узган юллар турында.

Зәңгәрләнеп аста елга ага,
Яр башында ялгыз кабердә
Дустым калды бездән аерылып
Күз алдымда барсы хәзер дә.
Янып-әрнеп авыр юксынудан
Йөрәк ярсый, йөрәк шашына.
Күңел тулган әче нәфрәт белән,
Алга киттек дошман каршына.
Киткән чакта кабереңә карап
Пилоткамны салып селтәдем.
Еллар узды, күпме юллар уздым
Синең амәнәтне үтәдем.
Насыйп булды миңа исән кайтып
Синең авылыңны күрергә.
Син сөйләгән Майна болынында
Туганнарың белән йөрергә.
Чәчләремә инде кырау төште,
Күңел һаман фронт кырында.
Мөмкин түгел һич тә онытырга
Шунда калган дуслар турында.
1996

ЮКСЫНУ
Мәктәп торган биек тауга карап
Ник юксына икән күңелем ?
Балаларга тәүге белем биреп
Узгангамы шунда гомерем ?
Көзләр җиткән саен сиңа киләм,
Нигез ташың гына калса да.
Ни булган соң тауда басып торсаң,
Истәлеккә генә булса да ?
Ак тәрәзә, зәңгәр капкаларың
Әйләнгәндер инде күмергә.
Балаларың сукмак өзмәс иде
Исән булсаң синнән гомергә.
Бакчаларың кыргый урман булган,
Коймаларың сүтеп алганнар.
Каеннарың тора башын иеп,
Гүя алар ятим калганнар.
Каеннарга карап басып торам,
Фикер йөри артта еракта.
Күз алдымнан уза барсы, кинәт
Җиз кыңгырау чыңлый колакта.
Яңа мәктәп – матур һәм зур бина,
Булып торам анда еш кына.

Әллә инде бергә картайганга,
Күңел никтер тегесен юксына...
1988

КЛАСС ҖИТӘКЧЕСЕ
Ничә тапкыр инде егет булдым.
Ничә тапкыр килде балачак.
Менә шулай алмашына килә
Күңел язым инде ничә кат.
Нәни дуслар белән дүртенчедән
Унынчыга кадәр үсәмен.
Үскәч дуслар китә, ә мин исә
Кабат дүртенчегә төшәмен.
Шулай итеп егет булгач кына,
Тагын кайта балачакларым,
Сабый белән сабый дигән кебек,
Балаларча яши башладым.
Чиратлашкан җәйләр, көзләр кебек,
Кабатлана тора гел шулай
Чигә чәчләремә чал керсә дә,
Алар белән күңел – шук малай.
Класс җитәкчесе менә шулай,
Чәче агарса да башында.
Бала белән бала була белә,
Егет була егет каршында.
1975

УКЫТУЧЫ КИТӘ ПЕНСИЯГӘ
Укытучы китә пенсиягә,
Дулкынлана күңел дәрьясы.
Узган юлы белән горурлана,
Ә күзләрнең моңсу карашы.
Күпме еллар узды, вакыйгалар,
Күпме сулар акты ярсынып.
Күпме төннәр үтте фикер йөртеп,
Күпме таңнар атты яктырып.
Хезмәт таңы ерак, артта калды,
Кабат кайтмас булып мәңгегә.
Искән җилдәй еллар буш узмады,
Еллар күмде аны дан белән.
Партия да аны тәбрик итә,
Тәбрик итә аны дәүләт тә.
Сәлам яза аңар Уфа, Казан,
Сәлам яза ерак Ташкент та.
Бакчачы да бакчасына кереп,

Җимешләрен күреп соклана.
Укытучы исә шәкертенең
Кеше булуына шатлана.
Ул укыткан яшьләр галим булып
Ил каршында шөһрәт казанды.
Ул укыткан яшьләр сугышларда
Горур якладылар Ватанны.
Ул укыткан яшьләр заводларда
Яңа җиңүләргә ирешә.
Ул укыткан яшьләр киң кырларда
Мул уңышлар өчен көрәшә.
Сау бул инде, мәктәп һәм балалар.
Нык тотыгыз безнең әләмне!
Сез төзәрсез илдә коммунизм,
Таң калдырып бөтен галәмне.
Укытучы китә пенсиягә.
Дулкынлана күңел дәрьясы.
Атлар иде алга һаман бергә,
Ах, яшьлеге кире кайтсачы.
Нишлисең бит, дөнья шулай инде,
Табигать ул шулай корылган.
Аккан сулар кире кайтмый дигән
Сүзләр килгән борын-борыннан.
Мәктәп, каласың дип дулкынланам,
Бергә атла һаман, горур бул!
Гомер буе илгә хезмәт итеп,
Ялга чыгу бик зур бәхет ул.
1975

## СӘЛАМ СИҢА, АБАЛАЧ!

Еллар узып, юлым күмелсә дә,
Искә алам яшьлек елларын.
Ерак-ераклардан әйләнә дә,
Сиңа кайта күңел юлларым.
Кояш чыккан чакта тауга менсәм,
Синең якларны да күзлимен.
Ничә еллар инде газетадан
Синең исемеңне күзлимен.
Тугайларың, көмеш чишмәләрең
Күз алдымда әле ал таңың.
Язның айлы тыныч кичләрендә
Тальян тарта иде Солтаның.
Изге мәктәп, бинаң, укучылар
Төшләремә әле керәләр.
Шат күңелле таныш балаларың

Бакчасында гүя йөгерәләр.
Күпер чыгам инешеңә карап,
Колагымда яңгырый шул сәгать.
Су буенда , имеш, алачыкта
Тимер суга чың-чың Сибагать.
Колхозыңда уңган егетләрең
Яңа төзелешләр төзиме?
Шәйхетдиннәр, Ризван, Кәшифләрең
Һаман шунда эшләп йөриме ?
Мәктәп ерак иде тау башында
Ул урыннан инде күчтеме?
Без барында яңа утыртылган
Мансур наратлары үстеме?
Оныткандыр димә, онытмадым.
Сәлам сиңа, сәлам, Абалач!
Таныш юлчың булып бер узармын
Сандугачың килгәч, яз булгач.
1977

## ҖЫРЫ КАЛДЫ

*Мәктәп елларында яратып укыткан укучым шагыйрь*
*Марсель Гыймазетдиновның якты истәлегенә*

Күтәрелеп күккә балкытты ул
Авылы офыкларын ялгызы.
Көтмәгәндә кинәт юкка чыкты
Авылыбызның якты йолдызы.
Йолдыз атыла да юкка чыга
Якты эз калдырып һавада.
Шагыйрь юкка чыкса җыры кала,
Мәңге ядкарь булып дөньяда.
1993

## СИНЕ ЭЗЛИМ

*Тормыш иптәшем Зәйтүнә Галиеваның якты истәлегенә.*

Сине эзлим чыклы чәчәкләрдән
Алсуланып таңнар атканда.
Сине эзлим төнбоеклы күлдән,
Тын офыкта шәфәкъ батканда.
Сине эзлим күктә йолдызлардан,
Җемелдиләр,гүя көләсең.
Кайсы синдер алар арасында,
Шуны эзлим, килә беләсем.
Сине эзлим акчарлаклар очкан
Дәрья буендагы камыштан.
Йөрәк әрнеп сыкрый, тынгы тапмый

Юксынудан, кайгы-сагыштан.
Сине эзлим бакчаларга чыгып.
Син утырткан гөлләр үскәннәр.
Чәчәкләрен күргәч искә төшә,
Бергә матур гомер иткәннәр.
Сине эзлим күктән, җирдән, судан,
Тик таба алмыйм, кая,кая син?
Көзге яфрак кебек саргаермын,
Таба алмасам һаман сине мин.
1999

САГЫНУ ХИСЛӘРЕ
Кайтырсың дип һәр көн көтәм
Иртәләрен , кичләрен.
Бер дару да басмый икән
Бу сагыну хисләрен.
Җәйнең җылы кичләре,
Җиләк-җимеш исләре.
Ул исләрдән дә көчлерәк
Миндә сагыну хисләре.
Сине эзләп барыйм микән
Кайсы ерак илләргә ?
Бер хәбәр дә алып килми
Иртән искән җилләр дә.
Нигә шулай атлам саен
Карыйм киткән ягыңа ?
Парлы кош та ялгыз калса,
Ямансулый, сагына.
Бакчадагы миләшемә
Бер былбыл сайрый кунып.
Көнем үтә сине сагынып
Тирән уйларга чумып.
Бергә чаклар искә төшеп
Йөрәкләрне яндыра.
Кабатланмас хыял булып
Үткәннәр сагындыра.
Һаваларда кошлар оча
Канатларын кагынып.
Айлар үтте, еллар узар,
Гомер үтәр сагынып.
1995

*Немец теле дәреслекләрендәге шигырьләр тәрҗемәләре*

ТЫНЫЧЛЫК КҮГӘРЧЕНЕ
Кечкенә ак күгәрченем
Оч ил өстеннән.
Һәр кешегә: зур, кечегә
Илт бездән сәлам.
Оч биек таулар өстеннән,
Диңгез, даладан.
Илт халыкларга тынычлык
Һәм сәлам бездән.
Сиңа теләк: хәерле юл,
Төшмә диңгезгә.
Күгәрченем , әйләнеп кайт
Тизрәк син безгә.

ТАПТЫМ
Урманга бардым тик болай гына.
Бер чәчәк күрдем тик шундый гына.
Җемелди матур, гел йолдыз үзе
Әйтерсең карый гел кеше күзе.
Теләдем аны өзеп алырга.
Ул әйтә миңа: өзмә, калдыр ла.
Син өзеп алсаң, мин шиңәрмен бит,
Озак яшәмәм, мин үләрмен бит.
Тамыры белән казып алдым да,
Өйгә ашыктым, хәтсез юл алда.
Бакчага кереп утыртып куйдым,
Су сибеп аңар, зур үс, гөл, дидем.
Хәзер үсә ул шул тын урында,
Чәчәккә бата һәр ел язында.

ҺӘР ҖИРДӘ ТЫНЛЫК
Урман тынган.
Тибрәлмиләр яфраклар да.
Дөнья тынган,
Сайрамыйлар кош-кортлар да.
Кал беразга,
Тынга калган шул урман да.
Ял итәрсең
Хәйран калып син дә анда.
1975

*Юмористик шигырьләр*

## ЕГЕТ БЕЛӘН БАБАЙ

-Нигә мөшкел, әллә начармы эшең?
-Начар, бабай, күрсәтә күреш тешем.
Көндез дими, кич дими һәм төн дими,
Тәүлегенә бер көләргә дә бирми.
Ашау кая, йөгерә салкын, эссесе.
Сызлый башлый аскысы һәм өскесе.
Бер даруның аңа файдасы тимәс,
Үләм, бабай, бирче, зинһар бер киңәш.
-Эшләгәннең эше , улым, эш икән,
Менә врач куйган тешләр теш икән.
Йөгерми һич аңар салкын, эссесе,
Сызлый калса, шул секундта аласың,
Сау-сәламәт буласың да каласың.
Рәхәтләндем ничә еллар, кара аны,
Син дә шул врачка барып кара әле!
1989

## ВРАЧ КАРШЫНДА

Врач каршысында әби утыра,
Центнер гына булмас үлчәсәң.
-Алып узганчы дип сиңа килдем,
Киңәш бир,-ди, -кызым, ичмасам.
Төне буе эчем талаулады,
Күзләремә йокы кермәде.
Ике тапкыр валериан эчтем,
Ул да бер дә файда бирмәде.
Моңа кадәр әле белми идем,
Авырганны болай эч белән.
-Ашыкмыйча гына сөйлә, әби,
Нәрсә ашадың син кич белән?
-Башта ашадым инде өч өчпочмак,
Симез иттән генә пешкәнен,
Аны ашаганда чәй дә эчтек,
Белмим анысын күпме эчкәнне.
Картым кайткач бергә аш ашадык,
Дүрт- биш калҗа гына ит каптым,
Бер бокалдай томат согы эчтем,
Рәтен тапмадым мин ул сокның.
Картым белән малайларга бардык,
Анда бергә пилмән ашадык.
Кызларының туган көне икән,

Чәйләр эчтек, бәйрәм ясадык.
Ашаганым бар да яхшы ризык,
Хәмер эчмим, үзең беләсең.
Авыртырга болай бер сәбәп юк.
Һава алышына күрәсең...
-Тыңла, әби, врач киңәшләрен,
Мин әйткәнне үтәп кара әле:
Бүген кайт та сәхәр ашамыйча
Уразага кереп кара әле!..
1979

## КАРТАЙДЫМ

*(Нәни шаяру)*

Картайдым, мин, дуслар, картайдым,
Яшәргә тапмыйм һич чара.
Ниләр генә сөртеп карамадым,
Сакал, мыек һаман агара.
Тешне алыштырдым, күздә күзлек,
Колакка да таптым бер чара.
Чәчем агаруын агармады,
Коелды да бетте бичара.
Хәтер дигәненә хәтерең калыр,
Хәтер бутый иске-яңасын.
Бармагыма җепләр бәйләп йөрим,
Үзем белеп аның чамасын.
Кичә шулай бутап Зәйтүнәмә
Мәймүнә дип дәштем, ләбаса!
Һәй , ябышты хатын битәрләргә,
Бер утыра үзе, бер баса.
Син , ди , картлач, әллә алышындың,
Әллә юкса тәмам узындың.
Миңа дәшәсең ич исеме белән
Яшь вакытта йөргән кызыңның!
Исем бутау ансы гаҗәп түгел,
Исем китеп аңар тормыймын.
Ярый әле яшь чак белән бутап
Мәймүнәне эзләп йөрмимен.
1988

## Тормышка гашыйк Фәйзелхак абый

Хөрмәтле дус! Менә Сез Фәйзелхак Гыйльфан улы Хөснетдиновның искиткеч гүзәл хисләр, уйлар, идеаллар, теләкләр, кичерешләр дөньясында булып чыктыгыз. Гади генә бер авыл укытучысы булып, гомер буе эшенә бирелеп чын күңелдән балаларга белем-тәрбия биргән, аларда Ватанга , туган җиргә, ата-анага, дусларга мәхәббәт тәрбияләп яшәгән кеше генә шундый матур шигырьләр иҗат итә ала.
Фәйзелхак абыйның исемен искә төшерү белән күз алдына тышкы кыяфәте, эчке дөньясы чибәр кеше килеп баса. Тик бу сүзләр генә аны характерлап бетерми әле. Бар булмышы, бар күзәнәге белән ул үзе сөйләгән фикерне көчәйтә, аны акыл белән генә түгел , күңел белән дә аңларга мәҗбүр итә: күзләр карашы да, иреннәр елмаюы да, салмак кына адымнары да, хәтта чәчләре, кигән күлмәге, мөлаем һәм җанга ятышлы тавышы да...
Фәйзелхак абый Бәзәкә авылында 1916 елда туган. Җиде сыйныф белем алгач колхоз бакчасында эшләгән. Буш вакытларында армия сафларына китәчәк яшьләрне укырга-язарга өйрәткән. 1936 елда Алабуга педагогия институтына укырга кергән. Аны тәмамлагач Бондюг районына кайтып татар мәктәбендә  эшләгән. 1940 елда хәрби хезмәткә алынган. Бөек Ватан сугышын Карпат тауларында каршы алган. Сугышның төрле кырларында булып туган якларга 1946 елның июнендә генә кайткан. Башта Абалач, аннан соң Бәзәкә  мәктәбендә эшләгән. Лаеклы ялга чыкканчы туган мәктәбендә немец теле укытучысы булып эшләде. 1977 елда пенсиягә чыкты.
Фәйзелхак абыйның күп кенә фронт медальләре, Россия һәм Татарстан Мәгариф министрлыклары тапшырган Мактау грамоталары һәм башка истәлекле бүләкләре бар. Яраткан укытучының искә алырдай матур көннәре, якты истәлекләре бар. Аның яраткан туганнары, балалары, укучылары, бергә эшләгән хезмәттәшләре һәм күркәм шигырьләре бар.
Авырлыкларны күп күрде Фәйзелхак абый. Тик күңеле сынмады, бирешмәде. Чөнки тормышка гашыйк ул, Фәйзелхак абый. Шуңа күрә табигать матурлыгыннан, авылдашларының аңа күрсәткән хөрмәтеннән , балаларының игелегеннән тәм-ямь табып яши. Намусы һәм күңеле чиста, хисләре бай Фәйзелхак абый әкрен генә тормыш диңгезе буенча йөзә. Ходай Тәгалә аңа көч һәм илһам бирсен, иҗат серләрен тагын да күбрәк ачсын, озын гомер һәм сәламәтлек бүләк итсен иде!
Яңа иҗади уңышлар Сезгә, Фәйзелхак абый!

Сәләхетдин Таҗиев